ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР
_______________ с. Верхний Услон _______________

Югары Ослан муниципаль районында 25 нче майдан 25 нче июльгә кадәр җир эшләрен уздыруны тыю турында.

Казан шәһәрендә Татарстан Республикасында футбол буенча дөнья чемпионаты матчларын уздыру чорында һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе, Татарстан Республикасы Иминлек Советының, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссиянең, Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча Координацион киңәшмәнең, иминлекне тәэмин итү буенча региональ ведомствоара оператив штабның уртак утырышы беркетмәсен үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елның 25 маеннан 25 июленә кадәрге чорда Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яңа төзелеш алып барганда, комплексларны һәм аерым биналарны киңәйткәндә яисә реконструкцияләгәндә, юллар һәм күперләрне яңадан төзегәндә, яңа җирләр үзләштергәндә, мелиорация системаларын яңадан көйләгәндә электр тапшыру, элемтә, газүткәргечләр линияләре зарарлануларын булдырмау өчен җир эшләрен уздыруны тыярга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хакимзянов

Әзерләде һәм бастырды:
Макарова А. И.